КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘДӘНИ МИРАС
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.03.2026 Казан шәһәре 117-П

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү» дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кушымта итеп бирелә торган административ регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 23 сентябрендәге 470-п номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2026 елның 02 мартындагы 117-П номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү» дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан «Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү» дәүләт хезмәтен (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү тәртибен һәм стандартын билгели.

Кулланыла торган билгеләр һәм кыскартулар исемлеге шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

1.2. Дәүләт хезмәте гражданнарга, шәхси эшкуарларга, юридик затларга (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле) эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган мөрәҗәгать итүчеләрнең (мөрәҗәгать итүче вәкилләренең) категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты (алга таба – Комитет).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе булып дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә (алга таба – бәяләмә) тора, ул 6 нчы кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелә.

Бәяләмә Комитет бланкында рәсмиләштерелә.

Мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язуын формалаштыру каралмаган.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада кәгазь чыганакта мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) (техник мөмкинлек булган очракта) яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы).

үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ) аша.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алу өчен мөрәҗәгать итүче Комитетка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән Комитетка яисә почта аша бирелгән булса, дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы гариза һәм әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 15 эш көненнән дә артмый.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы гариза һәм әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 15 эш көненнән дә артмый.

2.4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь срогы гариза һәм әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән кимендә 15 эш көне тәшкил итә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү алу каралмаган.

2.6. Гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты

Гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират

көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты

2.7.1. Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза кергән көнне үк теркәлә.

2.7.2. Гаризаны почта аша җибәргәндә, гариза кергән көнне теркәлә.

2.7.3. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.7.4. КФҮ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза биргән көнне мөрәҗәгать итүчегә КФҮ автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаның җибәрелгәнлеген раслаучы теркәү номеры һәм аны тапшыру датасы белән язу бирелә.

Гарызнамәне һәм теркәлә торган документларны Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Комитетка тапшыру тәэмин ителә.

КФҮ аша килгән гариза һәм кушып тапшырылган документлар Комитетта алынган көнне теркәлә.

2.7.5. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналар туры килергә тиешле таләпләр Комитетның рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

Дәүләт хезмәтеннән файдалану һәм сыйфат күрсәткечләре Комитетның рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

КФҮләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.10.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Консультация мөрәҗәгать итүче бүлеккә шәхсән, телефон, электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә бирелергә мөмкин.

2.10.3. Дәүләт хезмәтен КФҮ аша күрсәтү КФҮ белән Комитет арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү булганда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы КФҮ аша экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

КФҮ дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны соратып алудан баш тарту турында карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документларны бирү, шулай ук, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне кәгазьдә төзүне һәм таныклауны да кертеп, документлар бирү каралган.

2.10.4. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

гаризаны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге 72 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

электрон рәвештә бирелгән гаризаны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Бердәм портал һәм (яки) Республикасы порталы ярдәмендә Комитет, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.10.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

Әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, түбәндәгечә бүленешләр белән:

мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар;

мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырылмый.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гаризаның һәм кирәкле документлар формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

а) гариза дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына тапшырылган;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза рәвешендә мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (төгәл түгел, дөрес яисә тулысынча тутырмау), шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә дә;

в) тапшырылган документлар дәүләт хезмәтен сорап мөрәҗәгать иткән вакытта үз көчен югалткан (шәхесне таныклаучы документ);

г) мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

д) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

е) электрон рәвештәге гариза һәм башка документлар электрон имза белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып имзаланган.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.12.3. Законнарда дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.12.4. Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең, дәүләт хезмәтен туктатып тору һәм бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган административ процедураны гамәлгә ашыру

(дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), дәүләт хезмәтен күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң мөрәҗәгать итүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бүлүне күздә тоткан административ процедура, мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасы, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә рөхсәт ителә торган административ процедурасы каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

гаризаны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.3. Дәүләт хезмәтен алгарышлы (проактив) режимда күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүчегә аның гаризасының әлеге Регламентта билгеләнгән статусы үзгәрүе турында хәбәр ителә

(гаризаны кабул итү һәм теркәү турында; мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) турында), шулай ук мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында санап үтелгән ысулларның берсе белән башкарырга тиешле алда торган адымнар һәм гамәлләр турында хәбәр ителә:

Бердәм портал ярдәмендә;

Республика порталы аша.

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле
җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни
экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы акты – Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан аттестацияләнгән дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын уздыру буенча эксперт тарафыннан төзелгән, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү турындагы документлар бүлеген эшләмичә эшләрне башкару мөмкинлеге яисә аларны үткәрү мөмкин түгеллеге турында нәтиҗәләрне үз эченә алган бәяләмә.

Бәяләмә – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

Гариза – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза.

Мөрәҗәгать итүче – хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирүне сорап мөрәҗәгать итүче физик зат, шәхси эшкуарны да кертеп, яки юридик зат.

Комитет – әлеге дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты.

Бүлек – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының археология бүлеге, бәяләмә проектын аның хезмәткәрләре әзерли.

Администрацияләү бүлеге – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының администрацияләү бүлеге, ул гаризаларны (почта аша, КФҮ аша һәм шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) һәм бәяләмәләрне терки.

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле – мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен тәкъдим итү буенча тиешле вәкаләтләргә ия затлар.

Бәяләмә проекты – дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проекты.

Регламент – хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты.

Бердәм портал – Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/);

Республика порталы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы ((https://uslugi.tatarsta№.ru/).

КФҮ – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре.

210-ФЗ номерлы федераль закон – «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон;

63-ФЗ номерлы федераль закон – «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон.

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

## Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

1 нче таблица. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре исемлеге

| Ва-риант № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Җир кишәрлегендә мәдәни мирас объектларының булуы яисә булмавы турында мәгълүматны үз эченә алган бәяләмә | Гражданин, шәхси эшкуар, шәхсән мөрәҗәгать иткән; | 1А |
| 2. | | Гражданин, шәхси эшкуар, законлы вәкил мөрәҗәгать иткән; | 2А |
| 3. | | Юридик зат, юридик зат исеменнән ышанычнамәсез эш итәргә хокукы булган зат; | 3А |
| 4. | | Юридик зат, ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат. | 4А |

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Документлар исемлеге | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза:<br>шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән форма буенча кәгазь чыганактагы документ рәвешендә;<br>Бердәм портал яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон рәвешенә тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла) | 1А, 2А, 3А, 4А | Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда); Республика порталы аша, Комитетка шәхсән; КФҮ аша; почта аша |
| 2. | мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта тапшырыла). Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат | 1А, 2А, 3А, 4А | Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда); Республика порталы аша, Комитетка шәхсән; КФҮ аша; почта аша |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | системасында исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә. | | |
| 3 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турында нигезләмә раслау хакында» 2024 елның 25 апрелендәге 530 номерлы карары белән расланган Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турында нигезләмә нигезендә рәсмиләштерелгән һәм көчәйтелгән квалификацияле имза белән имзаланган, PDF документ формасытнда йөртелә торган, электрон рәвештә беркетелгән барлык документлар һәм материаллар белән бергә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы акты (алга таба – ДТМЭ акты). ДТМЭ актында квалификацияле электрон имза штампы күрсәтелергә яки экспертлар имзасы ачкычларын раслый торган файл булырга тиеш. | 1А, 2А, 3А, 4А | Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда); Республика порталы аша, Комитетка шәхсән; КФҮ аша; почта аша |
| *Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен үзе тапшырырга хокуклы документлар* | | | |
| Мөрәҗәгать итүче үзе тапшырырга хокуклы документлар дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен каралмаган. | | | |

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге**

| № | Гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге | Мөрәҗәгать итүченең идентификаторы |
|---|---|---|
| 1. | хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру (шушы Регламентның 2.10 пункты нигезендә) | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 2. | хезмәт күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү өчен вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына тапшырылган | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 3 | Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза рәвешендә мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (төгәл түгел, дөрес яисә тулысынча тутырмау) | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 4 | дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, тапшырылган документлар (шәхесне таныклаучы документ, мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен таныклаучы документ, күрсәтелгән зат хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта) үз көчен югалткан. | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 5 | тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 6 | документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 7 | дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада тапшырылуы | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 8 | документларның бирелгән электрон үрнәкләре документ текстын тулы күләмдә укырга һәм (яисә) документның реквизитларын танырга мөмкинлек бирми | 1А, 2А, 3А, 4А |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 10 | мөрәҗәгать итүче әлеге Административ регламентның 1.2 пунктында билгеләнгән затлар даирәсенә керми | 1А, 2А, 3А, 4А |
| Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган | | |
| Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | | |

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисенә
кемнән: ____________________
(физик зат өчен: Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), шәхесне таныклаучы документның исеме, сериясе, номеры, бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән, телефон, электрон почта адресы; вәкил өчен: вәкил вәкаләтләрен раслаучы өстәмә документ; ШЭ өчен: өстәмә рәвештә ОГРНИП, ИНН; юридик зат өчен: тулы исеме, оештыру-хокукый формасы, ИНН, ОГРН)

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында үтенәм:

дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза актының тулы исеме: ________;

дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актын рәсмиләштерү датасы: ____________.

Кушымталар: барлык теркәлә торган документлар һәм материаллар белән дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза акты, SIG форматында экспертның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән беркетелгән файл, Башка документлар.

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмәне түбәндәгечә җибәрүегезне сорыйм (кирәклесен ассызыкларга):

кулга, __________________ адресы буенча почта аша, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша.

__ ______ _____ (имза, гаризаны бирү датасы: (ФИА (соңгысы – булган очракта))

Хуҗалык буенча үзләштерелергә
тиешле җир кишәрлегенә дәүләт
тарихи-мәдәни экспертизасы актына
бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 6 нчы кушымта

Кемгә: ___________________
(физик затлар өчен: Ф.И.А. (соңгысы - булган очракта), физик зат яки юридик затның тулы исеме)

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт
тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә

Хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актын бирү турында ________ № _________ гариза нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турында нигезләмә раслау турында» 2024 елның 25 апрелендәге 530 номерлы карары белән расланган Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турында нигезләмәнең 30, 31 пунктлары таләпләренә туры китереп, хуҗалык буенча үзләштерелергә тиешле җир кишәрлегенә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы актына бәяләмә бирү турында дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза акты каралды ____________________________________

(тарихи-мәдәни экспертиза актының тулы исеме)

_____________, Россия Федерациясенең Мәдәният министрлыгы тарафыннан аттестацияләнгән

(дата)

дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын уздыру буенча эксперт тарафыннан төзелде ___________________ (алга таба – ДТМЭ акты).

Ф.И.А. (атасының исеме – булган очракта)

Иҗтимагый фикер алышу барышында (кирәклесен ассызыкларга):
искәрмәләр һәм тәкъдимнәр килмәде;
түбәндәге кисәтүләр һәм тәкъдимнәр керде: _________________________________

(Комитетның искәрмәләре һәм позициясе күрсәтелә)

ДТМЭ актын, аңа беркетелгән документларны һәм материалларны карау нәтиҗәләре буенча экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән нәтиҗәләр белән килешү/ килешмәү турында карар кабул ителде.

Риза булмауның сәбәпләре: _________________ (риза булмау очрагында бер яки берничә вариантны сайлау:

экспертиза бәяләмәсенең мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарына туры килмәве;

экспертиза бәяләмәсен рәсмиләштергән көннән алып 3 еллык срокның тәмамлануы;

экспертиза үткәрүнең билгеләнгән тәртибен бозу;

экспертиза бәяләмәсенә кул куйган экспертка карата Нигезләмәнең 5 пунктында каралган хәлләрне ачыклау;

экспертиза уздыру өчен Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән, дөрес булмаган белешмәләр булган документларны тапшыру.

Өстәмә мәгълүмат (булган очракта): _____________

Рәис ___________________

(имза, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))